
Октябрь • 2020 ел • № 4 (34)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы





# Хәтер сагында



Сау-сәламәт кеше алдында туган илен, туган җирен саклау бурычы тора. Ватанны ярату төшенчәсе туган шәһәреңне ратудан, аның традицияләрен хөрмәт итүдән башлана. Быел без, 9–10 сыйныф укучыларыннан торган ике команда, Мәңгелек ут янында Пост №1 сакта тордык. Җитәкчебез Мөгинов Фаик Фоатович булды. Вахтаның икенче көнендә тантаналы рәвештә присяга кабул иттек. Бер атна эчендә чын хәрби тормыш мәктәбе уздык. Үзебездә төгәллек, пөхтәлек, тыйнаклык, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләдек. Сугыштан кайтмый калган шәһәрдәшләребезнең хәтерен саклау кебек изге миссиянең безгә йөкләнүе миндә горурлык хисләре уятты.

**Гөлнара ШАЕХОВА**







# Безнең УКЫТУЧЫЛАР

Күптән түгел бик матур бәйрәм – Укытучылар көне билгеләп үтелде. Әлбәттә, һәр елдагыча, укучыларның үзидарә командасы (җитәкчеләре Билалова Гөлсинә Хөснулла кызы белән берлектә) бик матур бәйрәм ясадылар. Ә сез безнең укытучыларыбыз турында беләсезме? Минем язмам безнең гимназия укытучыларының иҗатлары хакында булачак. Әйе, әйе, безнең гимназиядә укытучылар да матур итеп иҗат итә: кемдер шигырьләр язса, икенчеләре чигү чигә, өченчеләре агачтан уеп сыннар ясый, дүртенчеләре җырлар иҗат итә, бии, кыскасы, безнең гимназия укытучылары «Менә дигән!»нәр.

Җыр-моңга гашыйк укытучылар Шәйгарданова Ләйсән Зөфәровна, Зәйнуллина Әлфия Тәүфиковна, Закирова Сания Маликовна, Хаматова Ләйсәния Бариевна, Заһитова Зөлфия Мөхәммәтнуровна, Гиниятуллина Илфира Сабировналарның тырышлыклары белән гимназия укучылары сәхнә культурасына өйрәнәләр, җырлыйлар, бәйгеләрдә җиңеп кайталар. Әлеге укытучылар үзләре дә өздереп җырлыйлар, музыка уен коралларында уйныйлар.

Биюгә килгәндә, хореограф Гатина Лилия Вафировна җитәкләгән «Экспрессия» бию ансамбле чыгышы – гимназиядә узган һәр чараның матур бизәге. Шунысы кызык, күз алдында балаларның сәләтләре ачыла бара, биюләр елдан-ел камилләшә. Лилия Вафировна – биергә теләге булган һәр балага игътибарлы, шуңа күрә аның бию түгәрәгенә бик күп балалар тартылган. Ул үзенең ансамбле белән Мәскәү, Сочи калаларына барып, халыкара бәйгеләрдә җиңеп кайтты. Ел саен «Экспрессия» бию ансамбле үз чыгышын шәһәр тамашачысына күрсәтә, Сара Садыйкова исемендәге концерт залын тутырып чыгыш ясый.

Гимназия тормышына ямь өстәгән кешеләрнең берсе – алтын куллы балта остасы, хөрмәтле Фоат абый Закиров. Урам капкасыннан керү белән, безне агачтан ясалган арбалар, коелар, умарталар, җил тегермәннәре белән «Туган авылым» композициясе урнашкан мәйданчык каршылый, гүя авылның җылы мохиты гимназия итәгенә килеп сыенган. Әти-әниләр, кечкенә балаларын җитәкләп килеп, әлеге мәйданчыкта ял итәләр, балаларына татар халкының яшәү, хуҗалык итү рәвешен аңлаталар. Моннан тыш гимназия музеенда Фоат Вафиновичның шәхси күргәзмәсе куелган. Анда искиткеч төгәллек белән эшләнгән күз явын алырлык экспозицияләр урын алган.

Бездә Чаллы драма театры артистлары Шиһапова Энҗе Фрунзе кызы белән Садыйкова Чулпан Рифкать кызы җитәкләгән «Тылсым» түгәрәге эшләп килә. Әле оешканнарына ике генә ел узса да, алар үзләрен республикакүләм театр бәйгеләре җиңүчеләре итеп таныттылар. Гимназия укучылары белән танылган артистларның шөгыльләнүе – әти-әниләр өчен зур куаныч.

Галиева Алсу Икрамовна әзерләгән спектакльләр үзгә җылы, эчтәлекле, укучыларны бердәм итеп туплый торган итеп уйланылган булулары белән аеруча файдалы.

Татар теле, инглиз теле, башлангыч сыйныф укытучылары әзерләгән кичәләр, тамашалар, әдәби кичәләр балаларда иҗади куәсне үстерергә ярдәм итә, мәктәп тормышына төсләр колориты өсти.

Каләм тибрәтүче укытучылар кемнәр диярсез? Алар, әлбәттә, тел һәм әдәбият укытучылары: Харисова Энҗе Мирзануровна, Сәлимҗанова Нурзия Мифтаховна, Галиева Алсу Икрамовна, Валеева Суфия Василовна, Гиниятуллина Илфира Сабировна, Зарипова Альбина Әхмәтовна. Әлеге укытучыларның язмалары, шигырьләре матбугат битләрендә урын ала, һөнәри бәйгеләрдә бәяләнә. Харисова Энҗе Мирзануровнаның үзенең туган авыл тарихына багышланган «Туган төбәгем» исемле китабы басмага әзерләнә. «Мин дөньяны ачам», «Бергәләп укыйбыз», «Тәүге сынау», «Татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшчәнлек» җыентыкларында укучыларның һәм укытучыларның иҗатларын киң даирә укучыга тәкъдим итүем белән мин үзем дә горурланам.


Бисер белән матур бизәкле панолар ясаучы Ризванова Гөлназ Фәхрисламовна һәм Матвеева Лилия Фаилевна хакында язмый мөмкин түгел. Төгәллек, сабырлык таләп иткән әлеге шөгыль белән алар күптән мавыгалар, аларның эшләреннән сокланулы карашны алып булмый.


Иҗади укытучыларның һөнәри бәйгеләрдә катнашып җиңеп чыгуларына эчкерсез сөенәбез. Егорова Раушания Леонидовна, Фәттахова Алсу Миңнемөхәммәтовна, Хәлилова Гөлназ Флүсовна ел дәвамында «Иң дус сыйныф», «Ел укытучысы – 2020», «Педагог-психолог – 2020» бәйгеләренең һәр этабына видео-презентация, фәнни чыгыш, ачык дәрес әзерләп, финалда җиңүчеләр сафына бастылар. Аларга иҗади этәргеч һәм методик ярдәм күрсәткән Зиннурова Равилә Харисовна, Харисова Энҗе Мирзануровна хакында чын эзләнүчән иҗади остазлар дип әйтергә мөмкин.


Мәктәп бакчасында бик матур чәчәк үстерүче Шәймәрданова Әлфирә Биҗановна, Гәрәева Айсылу Сафиулловнаның күңел байлыклары хакында алар үстергән гөлләр сөйли.

Гомумән, матурлык, башлангычында кемдер торып, аның идеясен тирә-яктагылар дәррәү күтәреп алганда гына туа. Мөгаен, шуңа күрә дә, ярты ел эчендә гимназиягә нинди яхшы ремонт ясалгандыр. Гимназиянең ихлас күңелле җитәкчесе Гарифуллин Айдар Хәкимҗанович, Гисмиева Ризида Мөктәсыймовна җитәкчелегендә сабыр техник хезмәткәрләр, тырыш төзүчеләр һәм укытучылар коллективы көнне төнгә ялгап эшләгәнгә, укучылар матур, зәвык белән бизәлгән, җылы гимназиядә укыйлар, иҗат итәләр. Димәк, бердәмлектә безнең көч, ә иҗат шул бердәмлектән юл ала һәм чәчәк ата.

**Энҗе Әзһәм кызы НУРИСЛАМОВА**










# Блогерлар килде

Бүгенге көндә «Блогер кем ул?» дигән сорауны беренче сыйныф укучысына бирсәң дә, ул сиңа аңлатма бирә ала: Интернет челтәрендә даими рәвештә билгеле бер тематикага караган мәгълүмат (төрле формада булырга мөмкин) урнаштырып баручы кеше.

Гимназиягә Яр Чаллы шәһәре блогерлары киләчәк, дигәч, укучыларның күзләре янды.

Ремонттан соң яңартылган мәктәп белән танышып чыккач, блогерлар мәҗлесләр залында укучылар белән очрашуга керделәр. Блогерлар арасында төрле һөнәр ияләре бар икән, алар укучыларга белемнең ни дәрәҗәдә кирәк икәнлеген аңлаттылар. Килгән кунаклар арасында үзебезнең гимназияне тәмамлаган Эмиль абыйның булуы, аның гимназия тарихына бәйле истәлекләре белән уртаклашуы очрашуга җылылык төсе өстәде. «Үз инстаграмы, үз газетасы булган, уку өчен бөтен шартлар тудырылган гимназиядә уку сезнең өчен язмышның өчен зур бүләге, аның кадерен белеп укыгыз», – диде ул, чыгышын тәмамлап.

Алия НУРИСЛАМОВА

# Тагын бер очрашу

Октябрь аенда гимназиядә Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, Милли мөхтәрият рәисе Гыйльметдинов Илдар Ирек улы белән очрашу үткәрелде. Гимназиянең кунагы уку йортында туган телне өйрәнү өчен тудырылган шартлар белән танышты, «Минем гимназиям» газетасының архив саннарына, газета сериясеннән басылган җыентыкларга, китапханәнең фондына, туган телдә оештырылган түгәрәкләр эшчәнлегенә игътибар итте.



Очрашуның төп максаты – татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләренә ачыклык кертү. Илдар Ирек улы бу мәсьәләдә булган актуаль проблемалар белән уртаклашты, аларны чишү буенча катнашучыларның тәкъдимнәрен һәм фикерләрен тыңлады.

**Данис ДӘМИНОВ**



*«Гимназия күрке»*

# Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз



8 в сыйныф укучысы Гәрәев Риназ Worldskills профессиональ мастерлык ярышында Татарстан командасы составында катнашты, Мәскәү шәһәреннән килгән командадан өч баллга калышып, алар икенче урын яуладылар. Дүрт сәгать буена сузылган әлеге ярышта командалар роботның датчикларын дөрес тоташтырырга, программалаштырырга, эшләтеп күрсәтергә тиеш иделәр.

Әлеге җиңү өчен, Риназга узган елдан бирле В.Д. Поташов исемендәге колледжда атнасына өч тапкыр шөгыльләнергә, пандемия чорында онлайн-дәресләрдә укырга, җәйге каникулның көне ике атнасын гына ял итәргә туры килә. Тырыш классташыбыз Риназга уңышлар телибез, аның белән горурланабыз!

**Азалия ӘМИНОВА**

# Элегант яшьтәге укытучылар

Гомерләрен мәктәп тормышы белән бәйләгән ветеран укытучылар Өлкәннәр көне уңаеннан бәйрәм концертына кунак булып чакырылдылар. Татарстанның атказанган артисты Равил Галиев, Айгөл һәм Ришат Шәйхетдиновларның җырлары бәйрәмгә ямь өстенә ямь өстәде. Кыска гына вакыт эчендә танылып өлгергән, гимназиянең элекке укучысы Вәлиев Марат Минсабирович оештырган «Ике яр» ансамбле чыгышын барысы да җылы кабул итте. Концерт Лилия Әхмәтованың думбра уен коралында нәзакәтле итеп уйнавы, Лилия Вафировна җитәкләгән «Экспрессия» бию ансамбленең «Туган як» һәм «Кытай бизәкләре» биюләре, Зәйнуллина Әлфия Тәүфиковна җитәкчелегендәге «Әллүки» вокал ансамбле җырлары белән үрелеп барды. Төрле җыр бәйгеләрендә чыгыш ясап алдынгы урыннар яулаган гимназия укучылары Ишалина Әдиләнең «Әссәламегаләйкүм», Сахапова Солтанәнең «Туган тел», Мөхәммәтшина Индира башкаруында «Зәңгәр томан» җырлары, бәйрәмгә чакырылган кунак егет – Салават Сакаевның аерым осталык белән башкарган «Казах кызы» җыры залдагы тамашачыларның күңеленә аеруча хуш килде.



Кеше күңеленә бер җылы сүз җитә. Гимназиядәге бәйрәм концертларының даими алып баручылары – Сәйдәш Галиев һәм Айсылу Ишалинаның, видео-котлау әзерләгән Нурисламова Алиянең мөгаллимнәргә карата гимназия укучылар исеменнән әйтелгән самими теләкләре, эчкерсез рәхмәт сүзләре – аларга яшәргә көч бирсен, эшләргә дәрт-дәрман өстәгәндер. Аннан бөтен гимназия коллективы укытучылары истәлеккә фотосурәткә төштеләр. Бәйрәм кунак өстәле артында дәвам итте. Кунаклар бәйрәмнән, хезмәттәшләре белән очрашудан канәгать калдылар.

**Гөлсинә Хөснуловна БИЛАЛОВА**

# Күңелле бәйрәм



Бу уку елында, без класс белән бик күңелле итеп «Сөмбелә» бәйрәмен үткәрдек. Күзгә тематикага туры килерлек итеп кабинетны бизәдек; укучылар ясаган рәсемнәрне, аппликацияләрне, яшелчәләрдән ясалган фантастик фигураларны буйдан-буйга тезеп куйдык. Көз турында шигырьләр, җырлар өйрәндек. Сөмбелә бәйрәменең асылы хакында сыйныф сәгатендә чыгышлар ясадык. Безнең бәйрәмгә дә Сөмбелә килде. Сыйныфташларым, һәр ел фасылын чагылдыручы костюмнар киеп, тамаша да күрсәттеләр.

Бәйрәмнең дәвамы табын артына күчте, без берберебезне кыстый-кыстый, тәмләп чәй эчтек, аннан күңел ачтык. Бәйрәм бик күңелле булды.







**Диләрә БУЛАТОВА,**
*5б класс укучысы*

## Укучылар иҗаты

### Такмаклар

Мәктәпләргә барам әле,
«Бишле»ләр алыр өчен,
«Дүртле»ләр генә эләгә,
«Бишле» гә җитми көчем.
Кичтән үк йокларга яттым,
Иртән мәктәпкә, диеп.
Иртән йөгердем мәктәпкә,
Күлмәкне кире киеп.
Чыгып киттем мәктәпкә
Аркага букча астым,
Укытучы сорау биргәч,
Парта астына качтым.
Бу бит минем хакта түгел!
Ялгыш уйлый күрмәгез!
Ашык-пошык укып йөреп,
Хурга кала күрмәгез!

**Әмирхан АВДИМОВ,**
*5в класс укучысы*

Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. Ф. НУРИСЛАМОВА